**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.03.2023 № 162-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләүне оештыру турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 декабрендәге 2328 номерлы карары белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Билгеләргә:

әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына аларны уздыру өчен экспертларны җәлеп итү таләп ителә торган экспертизалар өлкәләре һәм аларга туры килә торган экспертиза төрләре исемлеген;

әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган мөрәҗәгать итүче белән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрыгы арасында административ процедураларның составы һәм хезмәттәшлек итү чорларын;

әлеге боерыкның 3 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү критерияләрен;

әлеге боерыкның 4 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләүнең гамәлдә булу чорын;

әлеге боерыкның 5 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларның реестрын төзү һәм алып бару кагыйдәләрен;

әлеге боерыкның 6 нчы кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертлар сыйфатында аттестация алуга дәгъва белдерүче гражданнар өчен квалификация имтиханын уздыру буенча Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аттестация комиссиясе турында нигезләмә;

әлеге боерыкның 7 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертны аттестацияләү турында гариза формасын.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Федераль дәүләт урман күзәтчелеге, урманнарда федераль дәүләт янгын күзәтчелеге чараларын уздыруга Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестатлау буенча Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының аттестатлау комиссиясе турында» 2018 елның 19 мартындагы 148-осн номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Юридик бүлек җитәкчесенә (В.В.Мәнихова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Н.Зариповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 20 мартындагы 162-осн боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына аларны уздыру өчен экспертларны җәлеп итү таләп ителә торган экспертизалар өлкәләре һәм аларга туры килә торган экспертиза төрләре исемлеге

Агач материалын кабул итү, ташу, эшкәртү һәм саклау һәм аны күзәтеп тору, агач материалын һәм аның белән алыш-бирешләрне исәпкә алу өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрдән тыш, Россия Федерациясе Урман кодексы, башка федераль законнар һәм аларга ярашлы рәвештә Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, торгызу һәм үрчетү өлкәсендә (шул исәптән урманнарда янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә), урман үсемлекләре орлыкларына карата орлыкчылык өлкәсендә кабул ителә торган таләпләрне юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан үтәп, урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда экспертиза

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 20 мартындагы 162-осн боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган мөрәҗәгать итүче белән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрыгы арасында административ процедураларның составы һәм хезмәттәшлек итү чорлары

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертиза үткәрүгә җәлеп ителә торган эксперт аттестациясен алуга дәгъва кылучы гражданин Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

- әлеге боерыкның 7 нче кушымтасында каралган форма буенча урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертны аттестацияләү турында гариза;

- әлеге боерыкка 3 нче кушымтада каралган экспертларны аттестацияләү критерияләренә туры килүен раслый торган документлар һәм (яки) белешмәләр, аларны үткәрү өчен Министрлыкка экспертларны җәлеп итү таләп ителә торган экспертиза өлкәләрен һәм төрләрен исәпкә алып (алга таба – документлар):

а) белем алуны раслаучы документларның күчермәләре, шулай ук (булганда) гыйльми дәрәҗә булуын раслаучы документларның күчермәләре, аттестатларның, сертификатларның, таныклыкларның күчермәләре;

б) хезмәт кенәгәсенең тиешле рәвештә расланган күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;

в) кандидатның аттестацияләү өчен белдерелгән эшчәнлек өлкәсендәге экспертизаларда катнашуын раслый торган һәм эксперт эшчәнлеген башкару сәләтен бәяләргә мөмкинлек бирә торган (булган очракта) документларның күчермәләре;

- «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

- Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2021 елның 24 февралендәге 18 номерлы боерыгы белән расланган Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык эчтәлегенә карата таләпләр нигезендә, тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

2. Аттестация турында гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка шәхсән тапшырыла яки кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы хат итеп юллана яисә, гариза «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша кергән очракта, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

3. Министрлык экспертны аттестацияләү турында гаризаны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә түбәндәгеләрне тикшерә:

а) экспертны аттестацияләү турындагы гаризаның әлеге боерыкка 7 нче кушымтада каралган экспертны аттестацияләү турындагы гариза формасына (алга таба – экспертны аттестацияләү турындагы гариза формасы) туры килүен;

б) әлеге кушымтаның 1 пунктында каралган документлар булуын.

4. Боерыкка әлеге кушымтаның 3 пунктында каралган тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) экспертны аттестацияләү турындагы гаризаны һәм документларны карап тикшерүгә кабул итү турында – боерыкка әлеге кушымтаның 3 пунктында күрсәтелгән таләпләр үтәлгән очракта;

б) экспертны аттестацияләү турында гаризаны һәм документларны карамыйча кире кайтару турында – боерыкка әлеге кушымтаның 3 пунктында күрсәтелгән таләпләр үтәлмәгән очракта.

5. Экспертны аттестацияләү турындагы гаризаны теркәгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлык мөрәҗәгать итүчегә экспертны аттестацияләү турында гаризаны карамыйча калдыру турында хәбәр итә һәм әлеге кушымтаның 4 пунктындагы «б» пунктчасында каралган очракта, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, тапшырылган документларны кире кайтара:

а) экспертны аттестацияләү турындагы гариза һәм документлар турыдан-туры тапшырылган очракта, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән;

б) гариза «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша кергән очракта, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында.

6. Экспертны аттестацияләү турындагы гариза һәм документлар карау өчен кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге документларны экспертны аттестацияләү турындагы гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң 10 эш көненнән артмаган чорда мөрәҗәгать итүченең урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга Министрлык тарафыннан җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләүнең әлеге боерыкка 3 нче кушымтада билгеләнгән критерияләргә (алга таба – экспертларны аттестацияләү критерияләре) туры килүе предметына карата тикшерә һәм боерык формасында түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) мөрәҗәгать итүчене аттестацияләүдән баш тарту турында – мөрәҗәгать итүче белеме һәм эш стажы буенча таләпләр өлешендә экспертларны аттестацияләү критерияләренә туры килмәгән очракта;

б) мөрәҗәгать итүченең квалификация имтиханына кертелүе турында – мөрәҗәгать итүче белеме һәм эш стажы буенча таләпләр өлешендә экспертларны аттестацияләү критерияләренә туры килгән очракта.

7. Боерыкка әлеге кушымтаның 6 пункты нигезендә кабул ителгән карар турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә аны кабул иткәннән соң бер эш көне эчендә боерыкның әлеге кушымтасындагы 5 пунктында каралган ысулларның берсе белән хәбәр итә.

8. Квалификация имтиханы уздырылган көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлык үзләренә карата квалификация имтиханына кертү турында карар кабул ителгән мөрәҗәгать итүчеләргә боерыкка әлеге кушымтаның 5 пунктында каралган ысулларның берсе аша квалификация имтиханын уздыру урыны, көне һәм вакыты турында хәбәр итә.

9. Боерыкка әлеге кушымтаның 8 пунктында каралган белдерүне алган көннән соң өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүче Министрлыкка турыдан-туры яисә заказлы почта юлламасы аша, яисә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә ирекле формада тутырыла торган түбәндәге гаризаларны (алга таба – гариза) җибәрә:

а) квалификация имтиханын үткәрү көнен һәм вакытын үзгәртү турында – аны аттестацияләү процедурасы кысаларында бер тапкырдан да артык түгел;

б) квалификация имтиханында читтән торып катнашу мөмкинлеген бирү турында – турыдан-туры формада квалификация имтиханын үткәрүгә комачаулаучы шартлар туган очракта.

10. Боерыкка әлеге кушымтаның 9 пунктында каралган гаризалар килгән очракта, Министрлык тиешле гаризаларны аларны теркәгән көннән соң өч эш көне эчендә карый.

Квалификация имтиханы читтән торып гамәлгә ашырыла торган технологияләр ярдәмендә уздырылган очракта, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә читтән торып кулланыла торган технологияләрне файдалану турында боерыкка әлеге кушымтаның 9 пунктының «б» пунктчасында каралган гаризаны теркәгән көннән соң өч эш көне эчендә хәбәр итә.

11. Квалификация имтиханы Министрлык тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертиза үткәрүгә җәлеп ителгән экспертны аттестацияләү турындагы гаризаны теркәгән көннән алып 45 эш көненнән артмаган вакытта үткәрелә.

12. Квалификация имтиханын үткәргәндә Министрлыкның урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертиза үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар сыйфатында аттестация алуга дәгъва кылучы гражданнар өчен квалификация имтиханын үткәрү буенча аттестация комиссиясе (алга таба – Комиссия):

- экспертлыкка кандидат тәкъдим иткән документлар белән таныша;

- экспертлыкка кандидатның тиешле эксперт эшләрен үткәрү өчен кирәкле теоретик һәм гамәли әзерлекләре, тәҗрибәсе, вәкаләте булуын бәяли.

13. Квалификация имтиханы кандидатның әлеге боерыкның 3 нче кушымтасында каралган аттестация критерияләренә туры килүен билгеләү өчен әңгәмә рәвешендә үткәрелә.

14. Квалификация имтиханын үткәрү нәтиҗәләре буенча Комиссия мөрәҗәгать итүченең белемен бәяләү буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

аттестация критерияләренә туры килә;

аттестация критерияләренә туры килми.

15. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре Комиссия беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

16. Министрлык, Комиссия беркетмәсе нигезендә, квалификация имтиханын үткәргән көннән соң 10 эш көненнән дә артмаган срокта, боерык формасында түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) мөрәҗәгать итүчене аттестатлау турында, әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча аның экспертларны аттестатлауның әлеге боерыкка 3 нче кушымтада билгеләнгән критерияләренә туры килүе турында карар кабул ителсә;

б) квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча экспертны аттестацияләүнең әлеге боерыкка 3 нче кушымтада билгеләнгән критерияләренә туры килмәү турында карар кабул ителсә яисә әгәр мөрәҗәгать итүче квалификация имтиханында катнашмаса, мөрәҗәгать итүчене аттестацияләүдән баш тарту турында.

17. Министрлык мөрәҗәгать итүчегә боерыкка әлеге кушымтаның 16 пункты нигезендә кабул ителгән карар турында мондый карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә боерыкка әлеге кушымтаның 5 пунктында билгеләнгән ысулларның берсе белән хәбәр итә.

18. Министрлыкның һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 20 мартындагы 162-осн боерыгына 3 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү критерияләре

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертиза үткәрүгә җәлеп ителә торган эксперт статусын алуга дәгъва кылучы гражданнар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1.1. «Урман һәм урман-парк хуҗалыгы», «Урман инженерлыгы эше» әзерлек юнәлешләре яки Россия Федерациясенең мәгариф турындагы законнарында әлеге белгекчлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча ярашлылык билгеләнгән башка белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча бакалавр дәрәҗәсеннән ким булмаган югары һөнәри белем һәм (яки) «Урман һәм урман-парк хуҗалыгы», «Урман инженерлыгы эше» әзерлек юнәлешләре яки Россия Федерациясенең мәгариф турындагы законнарында әлеге белгекчлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча ярашлылык билгеләнгән башка белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча өстәмә һөнәри белем булуы;

1.2. Урман хуҗалыгы өлкәсендә кимендә биш ел эш стажы булу.

1.3. Экспертлыкка кандидат:

а) урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәүне тикшерү һәм экспертиза ясау күнекмәләренә, контроль (күзәтчелек) чарасында катнашу нәтиҗәләре буенча эксперт бәяләмәсен һәм башка документларны әзерләү буенча белемнәр һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш;

б) төрле мәгълүмат чыганаклары, мәгълүмат ресурслары һәм технологияләр белән эшләү, һөнәри эшчәнлектә компьютер техникасын, гамәли программа чараларын, заманча телекоммуникация чараларын, автоматлаштырылган мәгълүмат-белешмә, мәгълүмат-эзләтү системаларын, мәгълүмат базаларын куллану сәләте;

в) урман хуҗалыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне регламентташтыручы нормаларны үз эченә алган норматив хокукый актлар һәм локаль актлар белән эшләү;

г) шәхси мәгълүматлар белән эшләү;

д) тикшерү предметы буенча нәтиҗәләрне формалаштыру һәм нигезләү.

2. Экспертлыкка кандидат шәхси эшкуар булырга тиеш түгел.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 20 мартындагы 162-осн боерыгына 4 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләүнең гамәлдә булу чоры

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләүнең гамәлдә булу чоры биш ел тәшкил итә.

2. Эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турында карар Министрлык тарафыннан боерык формасында кабул ителә, түбәндәге очракта:

а) эксперттан аттестациянең гамәлдә булуын туктату турында гариза кергәндә;

б) экспертның үлеме турында белешмәләр алынганда;

в) Министрлык тарафыннан эксперт эшчәнлеге нәтиҗәләренең дөрес булмавы яисә объектив булмавы расланганда.

Эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турындагы карар Министрлык тарафыннан тиешле нигезләр барлыкка килгән көннән соң биш эш көне эчендә кабул ителә.

Министрлык мөрәҗәгать итүчегә әлеге пункт нигезендә кабул ителгән карар турында аны кабул иткән мизгелдән соң өч эш көне эчендә хәбәр итә.

Министрлык эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турында карар кабул иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә һәм Министрлык экспертлары реестрында бастыруга ризалык кире алынган дип санала.

Эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турында карар кабул ителгәннән соң ике эш көне эчендә Министрлык экспертны аттестацияләү турындагы белешмәләрне реестрдан төшереп калдыра.

3. Министрлык әлеге боерыкка кушымтаның 2 пунктындагы дүртенче абзацында каралган нигезләр буенча эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турында карар кабул иткән эксперт тиешле карар кабул ителгән көннән соң бер ел узгач кына Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

4. Эксперт Министрлыкка дәүләт граждан хезмәтенә кергән очракта, Министрлык тарафыннан эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул ителә.

Эксперт Министрлыкка дәүләт граждан хезмәтенә керү өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшырган көннән дә соңга калмыйча, аттестациянең гамәлдә булуын туктатып тору турында үтенеч белән Министрлыкка ирекле рәвештә төзелгән гаризаны җибәрә.

Эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар эксперт Министрлыкка дәүләт граждан хезмәтенә кергән көнне боерык рәвешендә кабул ителә, бу хакта мәгълүмат реестрда урнаштырыла.

Мондый экспертны урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертиза үткәрүгә җәлеп итү Министрлыкта дәүләт гражданлык хезмәте үткәндә мөмкин түгел.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 20 мартындагы 162-осн боерыгына 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларның реестрын төзү һәм алып бару кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Министрлык (алга таба – Министрлык) тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертиза үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертлар реестрын (алга таба – Реестр) төзү һәм алып бару тәртибен, шул исәптән Реестрга кертелә торган мәгълүматлар составын һәм Реестрдан мәгълүмат бирү тәртибен билгели.

2. Реестрны төзү һәм алып бару Министрлыкның дәүләт контроле һәм күзәтчелек бүлеге тарафыннан электрон формада башкарыла.

3. Министрлыкның экспертны аттестацияләү турындагы карары, шулай ук эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турындагы карары Реестрга экспертлар турында белешмәләр кертү өчен нигез булып тора.

4. Реестрда түбәндәге белешмәләр була:

а) язуның теркәү номеры;

б) эксперт турында мәгълүматны Реестрга кертү датасы;

в) экспертның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

г) аларны үткәрү өчен эксперт җәлеп ителә торган экспертиза өлкәсе, экспертиза төре;

д) экспертны аттестацияләү турында боерык номеры һәм датасы;

е) эксперт аттестациясенең гамәлдә булу вакытының тәмамлану датасы;

ж) эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктатып тору турында боерык номеры һәм датасы;

з) эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турында боерык номеры һәм датасы.

5. Министрлык Реестрга белешмәләр кертүне өч эш көненнән дә артмаган срокта тәэмин итә:

а) аттестация турында, аттестациянең гамәлдә булуын туктатып тору яисә туктату турында карарлар кабул итү көненнән соң;

б) Реестрга кертелгән белешмәләргә үзгәрешләр турында мәгълүмат кергән көннән соң.

6. Реестрда булган белешмәләр алар белән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар танышып чыгу өчен ачык булып тора, Россия Федерациясе законнары нигезендә файдаланылуы чикләнгән мәгълүматларга караган белешмәләрдән тыш.

7. Министрлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында реестрдан ачык белешмәләр урнаштыра.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 20 мартындагы 162-осн боерыгына 6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертлар сыйфатында аттестация алуга дәгъва белдерүче гражданнар өчен квалификация имтиханын уздыру буенча Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аттестация комиссиясе турында нигезләмә

1.Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертлар сыйфатында аттестация алуга дәгъва белдерүче гражданнар өчен квалификация имтиханын уздыру буенча Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аттестация комиссиясе (алга таба – Комиссия) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гражданнарны аттестацияләү өчен оештырыла.

2. Нигезләмә комиссиянең эш тәртибен билгели.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү тәртибе турында» 2020 елның 29 декабрендәге 2328 номерлы карарына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Комиссиянең составы Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән раслана.

5. Комиссия рәис, аның урынбасары, сәркатип һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.

6. Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Комиссия утырышының көнен һәм көн тәртибен билгели һәм раслый, Комиссия утырышларына рәислек итә һәм тиешле документларга кул куя.

Комиссия рәисе булмаганда, аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

8. Комиссия сәркатибе Комиссия эшен тәэмин итә, шул исәптән Комиссия әгъзаларына утырышларның датасы һәм вакыты турында хәбәр итә, Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча эш алып бара, материалларны саклауны һәм аларны архивка тапшыруны тәэмин итә, Комиссиянең эш тәртибе һәм аттестацияләү мәсьәләләре буенча гражданнарга консультацияләр бирә.

9. Комиссия эшчәнлегенең төп формасы булып квалификация имтиханнары үткәрелә торган утырышлар тора.

10. Квалификация имтиханы экспертлыкка кандидатның квалификациясен тикшерү максаты белән үткәрелә. Квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча Комиссия кандидатның экспертларга аттестация критерияләренә туры килүе яисә туры килмәве турында карар кабул итә.

11. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия, әгәр утырышта аның әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

12. Комиссия карары Комиссия утырышы көненнән соң өч эш көне эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия беркетмәсе комиссия сәркатибе тарафыннан алып барыла һәм Комиссия рәисе һәм утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары тарафыннан Комиссия утырышы уздырылган көнне имзалана.

13. Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышын үткәрү көне;

б) Комиссия утырышы беркетмәсенең номеры;

в) Комиссия әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, атасының исеме (булган очракта);

г) квалификация имтиханында катнашкан мөрәҗәгать итүчеләрнең фамилияләре, исемнәре, ата исемнәре (булган очракта);

д) квалификация имтиханы нәтиҗәләре һәм Комиссия әгъзаларының тавыш бирү нәтиҗәләре, мөрәҗәгать итүчеләрнең аттестация критерияләренә туры килүе/туры килмәве турында;

е) мөрәҗәгать итүчеләрнең квалификация имтиханына килмәве турында билге;

ж) мөрәҗәгать итүче тарафыннан квалификация имтиханын үткәрү тәртибен бозу турында билге;

з) Комиссия әгъзаларының аерым фикере булуы турында билге.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 20 мартындагы 162-осн боерыгына 7 нче кушымта

Татарстан Республикасы урман
хуҗалыгы министрына

______________________________

______________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме,
атасының исеме (булган очракта))

______________________________
(яшәү урыны адресы)

______________________________
(шәхесне раслаучы документы, ИНН)

______________________________
(телефон номеры)

______________________________
(электрон почта адресы)

## Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган экспертны аттестацияләү турында гариза

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) максатларында экспертизаны гамәлгә ашыруга җәлеп ителә торган эксперт сыйфатында аттестация уздыруыгыз турында үтенәм.

Шәхси эшкуар буларак теркәлмәвем турында хәбәр итәм.

Кушымталар:

- белем алуны раслаучы документларның күчермәләре, шулай ук (булганда) гыйльми дәрәҗә булуын раслаучы документларның күчермәләре, аттестатларның, сертификатларның, таныклыкларның күчермәләре;

- хезмәт кенәгәсенең тиешле рәвештә расланган күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;

- кандидатның белдерелгән эшчәнлек, өлкә һәм экспертиза төре өлкәсендәге экспертизаларда катнашуын раслый торган һәм эксперт эшчәнлеген башкару сәләтен бәяләргә мөмкинлек бирә торган (булган очракта) документларның күчермәләре.

- «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

- Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2021 елның 24 февралендәге 18 номерлы боерыгы белән расланган Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык эчтәлегенә карата таләпләр нигезендә, тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

| _______________ | _________________ | /______________________________/ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |